**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында» 2022 елның 12 апрелендәге ПУ-266 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында нигезләмәдә:

6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ведомствоара комиссия килгән үтенечнамәне чираттагы утырышта карап тикшерә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:»;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Республика исемен бирү турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Рәисенә мөрәҗәгатьне ведомствоара комиссия тиешле карар кабул ителгән көннән 30 календарь көн дәвамында юллый.»;

бишенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты кул куйган» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе кул куйган» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен бирү турында таныклыкның тасвирламасында:

бишенче абзацта «ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» һәм «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ» сүзләрен «РАИС РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» һәм «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» сүзләрен «РАИС РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ» сүзләрен «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Президента Республики Татарстан» сүзләрен «Раиса Республики Татарстан» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты имзасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе имзасы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президентының фамилиясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең фамилиясе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 25 апрель
№ 256